СОВЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа, Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАЛАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы, Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы**

**Наласа авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«10 » сентябрь 2026 ел** **№ 21**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының “Наласа авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 64 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (2023 елның 24 апрелендәге 76 номерлы үзгәрешләр белән)**

“Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Арча муниципаль районының “Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Наласа авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Советының “Наласа авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2022 елның 24 октябрендәге 64 номерлы карары белән расланган (2023 елның 24 апрелендәге 76 номерлы үзгәрешләр белән) Наласа авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Депутатның вәкаләтләре ул сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш муниципаль берәмлекнең тулы хокуклы составындагы вәкиллекле органының беренче утырышын уздырган көннән туктатыла.”.

2. Әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы Шакирова И.Р